ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**21.02.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 488**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2022 елның 08 декабрендәге 3393 номерлы карары белән расланган, Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле Зеленодольск муниципаль районы вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану турында» 2020 елның 19 ноябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2022 елның 08 декабрендәге 3393 номерлы карары белән расланган, Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле Зеленодольск муниципаль районы вазыйфаи затлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. кушымтадагы «Вазыйфаи затлар исемлеге» баганасында 1 нче, 10 нчы, 11 нче, 12 нче, 15 нче, 16 нчы пунктларын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«- ТР Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлегенең баш белгече»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге башлыгына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин